**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Арча муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, Советы мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районы**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

---

# Арча шәһәр Советы
# КАРАРЫ

«28» сентябрь **2021 ел** **№ 47**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Арча шәһәр Советының 2018 елның 13 августындагы 99 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (20.12.2018 №113, 30.12.2020 №23 үзгәрешләр белән)**

«Территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Арча шәһәр Советының 2018 елның 13 августындагы 99 номерлы карарына (20.12.2018 №113, 30.12.2020 №23 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12 статьяның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар (алга таба - җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев